**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлегенең **Түбән Кәминкә** торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

17 октябрь 2025 ел № 4

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең **Түбән Кәминкә** торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2026 елда Түбән Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булганнардан тыш

Алынган чараларны түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин алу, триммер һәм запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, иминиятләштерү һәм техник күзәтү үткәрү өчен түләү, халыкның һәм оешмаларның массакүләм ялы өчен шартлар тудыру, җәмәгать урыннарын төзекләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) табличкалар (күрсәткечләр) ясау һәм урнаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, **Түбән Кәминкә** торак пунктында хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (**Түбән Кәминкә** торак пунктында урамнарны яктырту өчен кулланыла торган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

**- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау** (янгын гидрантларын, янгын җиңсәләрен сатып алу һәм урнаштыру, **Түбән Кәминкә** торак пунктында алар өчен күрсәткеч табличкаларын әзерләү һәм урнаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Халиков